РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Б.Нырты, ул. М Джалиля, д.13
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М Җәлил урамы, 13 йорт
тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru

---

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР
18.10.2023　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　№31

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 26.11.2019 №27 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә туры китереп һәм федераль законнарның үзгәрүенә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советы

Карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» 26.11.2019 №27 карарының 1.2 пункты 1.2.2 пунктчасында «объектлары” сүзләрен “һәм (яки) объектлары” сүзләре белән алыштырырга, “объектка туры килә торган җир участогына хокуклы өлешне” сүзләрен «күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлеше» сүзләре белән алыштырырга, “һәм объектларга” сүзләрен “һәм (яки) объектларга” сүзләре белән алыштырырга.
2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3. Әлеге карарны Олы Нырты авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда игълан итәргә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

Авыл җирлеге башлыгы　　　　　　　　　　　　Р.З.Сәфәргалиев